# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АПАС ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
# КАРАРЫ

2021 ел, 14 апрель №41

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге советы депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2008 елның 25 нче декабрендәге "Коррупциягә каршы көрәш турында" 273-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Апас шәһәр җирлеге советы карар бирә:

1.«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Апас шәһәр җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмә хакында» 2017 елның 7 августындагы 78 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль вазыйфаны биләүче зат ел саен Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срокта түбәндәгеләрне тапшыра:

1) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан алынган керемнәре (акчалата бүләкләүне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, шулай ук аның милек хокукындагы мөлкәте турында һәм хисап чоры ахырына торышы буенча мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр (31 декабрьдә);

2) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) алган хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) керемнәре турында белешмәләр, шулай ук аларның милек хокукындагы мөлкәте турында һәм хисап чоры ахырына аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр (31 декабрь);

3) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, хисап чорына цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алуга кагылышлы алыш-биреш буенча үз чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары хакында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге соңгы өч елда шушы затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артса һәм әлеге алыш-бирешләрне башкару чыганаклары хакында.»;

2) түбәндәге эчтәлекле 2.2 пункт өстәргә:

«2.2.Җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес һәм тулы булмаган белешмәләр биргән депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим түгел икән, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) җирле үзидарәнең сайланулы органы депутатын муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфасыннан азат итү, аның вәкаләтләре чоры тәмамланганчыга кадәр, җирлек Советында вазыйфа биләү хокукыннан мәхрүм итү;

3) даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү, аның вәкаләтләре вакыты беткәнчегә кадәр даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итү.;

4) үз вәкаләтләре чоры туктатылганчы җирлек Советында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфалар биләүне тыю;

5) вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкаруны тыю.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Башлык урынбасары Исмәгыйлев Н.Т.